РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Краснокадкинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423558, Нижнекамский район,
с. Верхние Челны, ул. Молодежная, 13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Кызыл Чапчак авыл жирлеге
Башкарма комитеты

423558, Түбән Кама районы,
Югары Чаллы авылы, Яшьлэр урамы, 13

тел./факс (8555) 44-50-21, электронный адрес: Krasnokadkin.sp@tatar.ru, сайт: www.krasnokadkinskoe-sp.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 30 сентябреннән №36

Белешмә (өземтә)бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнеӊ административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә карар бирәм:

1. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнеӊ административ регламентын теркәлгән редакциядә (кушымта) расларга.
2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге башкарма комитетының«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан йорт биләүгә белешмә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнеӊ Административ регламентын раслау турында» 2012 елның 28 декабрендәге 41 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны җирлек уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәренеӊ җирлек сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Б.В.Ильдарханов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Кызыл Чапчак авыл җирлеге
башкарма комитетының
2019 елның 30 сентябреннән
36 номерлы карары белән
раслангankушымта

**Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба - муниципаль хезмәт күрсәтү).

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүне алучылар: физик затлар (алга таба-гариза бирүчеләр).

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1.Башкарма комитетның урнашкан урыны: ТР, Түбән Кама районы, Олы Кызыл Чапчак авылы, Яшьләр урамы, 1 нче йорт.

| Эш режимы: | Гражданнарны һәм юридик затларны кабул итү режимы: |
|---|---|
| Дүшәмбе-җомга 9.00 - 16.00 сәг.<br>Шимбә, якшәмбе – ял көне.<br>Төшке аш 12.00 - 13.00 сәг.<br>Керү ирекле | Сишәмбе, чәршәмбе, җомга 9.00.-16.00 сәг.<br>Төшке аш 12.00 - 13.00 сәг.<br>Дүшәмбе, пәнҗешәмбе документлар белән эш<br>Шимбә, якшәмбе – ял көне.<br>Керү ирекле |

Белешмә өчен телефон 8(8555) 44-50-20.

1.3.2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: (http://krasnokadkinskoe-sp.ru)

Башкарма комитетның электрон адресы: E-mal: krkadka-sp@mail.ru

1.3.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында, шулай ук Башкарма комитетның урнашу урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Гариза бирүчеләр белән эшләү өченБашкарма комитет биналарында урнашкан муниципаль хезмәт күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматларны үз эченә алган мәгълүмати стендлар ярдәмендә.

Татарстан Республикасының дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.9, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүматны үз эченә ала;

2) Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» челтәре аша (http://krasnokadkinskoe-sp.ru);

3) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi. tatarstan.ru/);

4) Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләр) бердәм порталында (http:// www.gosuslugi.ru/);

5) Башкарма комитетта:

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазьдә почта аша, электрон формада электрон почта аша.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Башкарма комитет тарафыннан Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өченБашкарма комитет биналарындагы мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Граждан кодексы, 30.11.1994,№51-ФЗ(Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 05.12.1994, №32, 3301 ст.) (алга таба-РФ ГК);

Россия Федерациясе Җир кодексы, 25.10.200, № 136-ФЗ (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 29.10.2001, №44, 4147 ст.) (алга таба – РФ ҖК);

Россия Федерациясе Торак кодексы, 29.12.2004, №188-ФЗ (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 03.01.2005, № 1 (1 өлеш), 14 ст. (алга таба-РФ ТК);

Нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләре (РФ ЮС рас., 11.02.1993 ел, № 4462-1) (Российская газета, № 49, 13.03.1993) (алга таба-нотариат турында закон нигезләре));

«Ветераннар турында»Федераль закон, 12.01.1995 ел, №5-ФЗ (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 16.01.1995, № 3, 168 ст.) (алга таба-5-ФЗ);

«Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль закон, 13.07.2015, № 218-ФЗ («Российская газета», 17.07.2015, № 156) (алга таба-218-ФЗ);

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль закон, 24.11.1995,№181-ФЗ («РФ законнары җыелмасы», 27.11.1995, № 48, 4563 ст.) (алга таба – 181-ФЗ);

«Крестьян (фермер) хуҗалыгы турында» Федераль закон,11.06.2003,№74-ФЗ (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 16.06.2003, № 24, 2249 ст.) (алга таба-74-ФЗ);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 06.10.2003, №40, 3822 ст.) (алга таба - 131-ФЗ);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон, 27.07.2010 ел, №210-ФЗ (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 02.08.2010, №31, 4179 ст.) (алга таба-210-ФЗ);

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Җирлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан хуҗалык китапларын алып бару формасын һәм тәртибен раслау турында» 2010 елның 11 октябрендәге 345 номерлы боерыгы (федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, № 50, 13.12.2010) (алга таба – 345 нче боерык);

Росреестрның«Җир кишәрлегенә гражданинның хокукы булу турында хуҗалык кенәгәсеннән өземтә формасын раслау турында» 2012 елның 7 мартындагы П/103 номерлы боерыгы белән ("Российская газета", № 109, 16.05.2012)(алга таба-Росрегистрация боерыгы);

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Республикасы, №155-156, 03.08.2004) (алга таба –45-ТРЗ);

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге Советы 2014 елның 6 июнендә кабул иткән 12 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Кызыл Чапчак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән.

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган белешмә (өземтә) астында гаилә составы турында белешмә, яшәү урыныннан белешмә, хуҗалык кенәгәсеннән өземтә, йорт кенәгәсеннән өземтә, вафат булучының вафат булу көненә яшәү урыныннан белешмә, шәхси торак йортларда яшәүчеләрдән алдагы яшәү урыныннан белешмә, йорт биләүгә белешмә аңлашыла.

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең ерак урнашкан эш урыны - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376нчы номерлы карары белән расланган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) шәһәр яки авыл җирлегендә төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең территориаль ае-рымланган структур бүлекчәсе (офис).

техник хата-муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка кертелгән мәгълүматның (муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе)алар нигезендә мәгълүмат кертелгән документлардагы мәгълүматка туры килмәүгә китергән хата (ялгыш язу, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә башка шундый хата).

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза) астында муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорау аңлашыла (210-ФЗ 2 ст. 2 п.). Гариза стандарт бланкта тутырыла (1 нче кушымта).

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартынаа таләпләр исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү исеме | Белешмә (өземтә) бирү | РФ ГК, РФ ҖК, РФ ТК, Нотариат турында закон нигезләре, 218-ФЗ, 74-ФЗ, 210-ФЗ, авыл җирлеге Уставы |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарә башкарма-боеру органы исеме | Башкарма комитет | авыл җирлеге Уставы |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләренең тасвирламасы | Белешмә (өземтә).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат | РФ ГК, РФ ҖК, РФ ТК, Нотариат турында закон нигезләре, 218-ФЗ, 74-ФЗ, 210-ФЗ, авыл җирлеге Уставы |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып,туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору | Гариза теркәлгәннән соң өч көннән дә артык түгел[1].<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган | РФ ГК, РФ ҖК, РФ ТК, Нотариат турында закон нигезләре, 218-ФЗ, 74-ФЗ, 210-ФЗ, авыл җирлеге Уставы |

[1]Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы административ процедураларны гамәлгә ашыру өчен минималь кирәкле суммар сроктан чыгып билгеләнгән. Административ процедураларның озынлыгы эш көннәрендә исәпләнә.

| | | |
|---|---|---|
| срогы | | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның, шулай ук гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүнең тулы исемлеге,мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тәкъдим итү тәртибе | Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза.<br>Документлар (оригиналлар) (2 нче кушымта).<br>Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Башкарма комитетта шәхси мөрәҗәгать иткәндә ала ала. Бланкның электрон формасы җирлекнең рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм кушып бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче зат тарафыннан);<br>почта аша җибәрелгән.<br>Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми керүгә рөхсәт ителгән мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрләре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре һәм Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | РФ ГК, РФ ЖК, РФ ТК, Нотариат турында закон нигезләре, 218-ФЗ, 74-ФЗ, 210-ФЗ |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы муниципаль хезмәт күрсәтүләр өчен норматив хокукый актлар нигезендә | Әлеге категориягә кертелергә мөмкин булганнарга документлар бирү кирәк түгел. | 210-ФЗ |

| | | |
|---|---|---|
| кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма; | | |
| 2.7. Хезмәт күрсәтү өчен һәм муниципаль хезмәт күрсәтү органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган,норматив хокукый актларда каралган очракларда,аларны килештерү кирәк булган дәүләт хакимияте органнары (җирле үзидарә органнары) һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне килештерү таләп ителми | 210-ФЗ |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) Документларны тиеш түгел зат тарафыннан тапшыру;<br>2) Документларны тиеш түгел органга тапшыру | 210-ФЗ |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>1) Гариза бирүче тарафыннан документлар тулы күләмдә тапшырылмаган, яисә тапшырылган гаризада һәм (яки) документларда тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат бар<br>2) тапшырылган документларның әлеге | 210-ФЗ |

| | | |
|---|---|---|
| | регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>3) гаризада һәм гаризага кушып бирелә торган документларда килешенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген бер мәгънәдә аңлатырга мөмкинлек бирми торган җитди зыяннар бар | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | 210-ФЗ |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми. | 210-ФЗ |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь срогы | Чират булган очракта муниципаль хезмәт алуга гариза бирү - 15 минуттан да артмый.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, чиратны максималь көтү срогы 15 минуттан артмаска тиеш | 210-ФЗ |
| 2.13Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирүченең соратуын теркәү срогы, шул исәптән электрон формада | Гариза кергән көнне | 210-ФЗ |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бүлмәләргә, мөрәҗәгать итүчеләрне көтеп тору һәм кабул итү урынына, шул | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән | 210-ФЗ,181-ФЗ |

| | | |
|---|---|---|
| исәптән инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.<br>Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеге («Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында»1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендәбинага уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә күчеп йөрү, транспорт чараларына түләүсез парковка өчен урыннар белән тәэмин итү) тәэмин ителә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |
| 2.15.Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең ерак эш урыннарында муниципаль хезмәт күрсәтү мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы | Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>Башкарма комитет бинасының җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге зонасында урнашуы;<br>гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган кирәкле санда урыннар булу;<br>мәгълүмати стендларда,«Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталындамуниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт алуга комачаулаучы каршылыкларны | 210-ФЗ,181-ФЗ |

| | | |
|---|---|---|
| турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кулланып | җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>документлар кабул итү һәм бирү өчен чиратлар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтләренә карата шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла. Хезмәттәшлек озынлыгы регламент белән билгеләнә. | |
| 2.16. Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципальхезмәткүрсәтүнеэлектронформада алутәртибетурындаконсультацияне Интернет-кабулитүбүлмәсеашаяисәТатарстанРеспубликасыд әүләтһәммуниципальхезмәтләрпорталыашаалырга мөмкин.<br>Әгәр законда муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза электрон формада бирелү каралса, гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша (http://uslugi.tatarstan.ru/) яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru/) аша бирелә. | 210-ФЗ |

**3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең ерак эш урыннарында административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре**

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә эш итү тәртибен тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:
1) гариза бирүчегә консультация бирү;
2) гариза кабул итү һәм теркәү;
3) муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен әзерләү;
4) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү.

3.2.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүне алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен гариза бирүчеБашкарма комитетка шәхсән һәм (яки) телефоннан мөрәҗәгать итә.

Башкарма комитет секретарегариза бирүчегә муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация бирә һәм кирәк булганда гариза тутыруда ярдәм күрсәтелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган документлар составы, формасы һәм эчтәлеге буенча күрсәтмәләр, консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән, ышанычлы зат аша белешмә (өземтә) бирү турында язмача гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны Башкарма комитетка тапшыра.

3.3.2. Башкарма комитет секретаре гамәлгә ашыра:

махсус журналда гаризаны кабул итү һәм теркәү;

гариза бирүчегәдокументларны кабул итү датасы, бирелгән керү номеры, муниципаль хезмәтне башкару датасы Һәм вакыты турындагы тамга белән гариза күчермәләрен тапшыру.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гамәлгә ашырыла:

гаризалар һәм документлар 15 минут эчендә кабул итү;

гаризаны кергән көнне теркәү.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.4. Соратып алынган документларны әзерләү һәм раслау (бирүдән баш тарту турында хатлар)

3.4.1. Башкарма комитет секретаре гамәлгә ашыра:

гаризага теркәлә торган документларның булу-булмавын тикшерү;

документлар (мәгълүматлар) булганда, белешмә (өземтә) проектын әзерләү;

документлар (белешмәләр) булмаганда, шулай ук Регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын әзерләү.

белешмә (өземтә) яки Башкарма комитет җитәкчесенә раслауга бирүдән баш тарту турында хат җибәрү.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать иткән мизгелдән алып ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмә (өземтә) яки бирүдән баш тарту турында хат проекты.

3.4.2. Башкарма комитет җитәкчесе белешмә (өземтә) яки бирүдән баш тарту турында хатны раслый һәм Башкарма комитет секретаренә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар узган процедураны тәмамлаганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: расланган белешмә (өземтә) яки бирүдән баш тарту турында хат.

3.5. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү

3.5.1. Башкарма комитет секретаре гариза бирүчегә журналда бирелгән белешмәләр (өземтәләр) алу турында имза белән белешмә (өземтә) яки баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп хат бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелгән белешмә (өземтә).

Әгәр мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алырга килмәсә, мөрәҗәгать итүчегә баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп хат белән, шулай ук телефон һәм (яки) электрон почта аша, баш тарту турында хат имзалаганнан соң бер көн эчендә хәбәр ителә.

3.6. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү, КФҮнең еракта торган эш урыны.

КФҮтә муниципаль хезмәт күрсәтү, КФҮнең еракта торган эш урыны бирелми.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсе буларак, документта техник хаталар ачыкланган очракта, гариза бирүче Башкарма комитетка тапшыра:

техник хаталарны төзәтү турында гариза (3 нче кушымта);

гариза бирүчегә техник хата булган муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән документ;

юридик көчкә ия, техник хаталар булуын таныклаучы документлар.

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсе буларак, документта күрсәтелгән мәгълүматларда техник хаталарны төзәтү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталы аша бирелә .

3.7.2. Документларны кабул итү өчен җаваплыБашкарма комитет секретаре техник хаталарны төзәтү турында гариза кабул итә, гаризаны терки.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.7.3. Башкарма комитет секретаре документларны карый һәм документка хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган төзәтүләр кертү максатында, әлеге Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хата булган документның төп нөсхәсен алып, гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә),имза куйдырып, шәхсән төзәтелгән документны бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хатаны ачыклаганнан соң яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары.

4.1.Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

1)муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2)билгеләнгән тәртиптә башкарыла торган эшләр башкаруын тикшерү;

3)билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен контроль тикшерүне үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы булырга мөмкин (җирле үзидарә органы эшенең ярты еллык яки еллык планы нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда, муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр), яисә гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча мәсьәләләр карала ала.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр кылуга контрольне һәм карарлар кабул итүгә контрольне гамәлгә ашыру максатларында, Башкарма комитет җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеген агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контроль муниципаль хезмәт күрсәтүче Җирлекнең секретаре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Башкарма комитетҗитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен вакытында карап тикшермәгән өчен җаваплылык тота.

Башкарма комитет секретаре әлеге Регламентның III бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең вакытында һәм (яки) тиешенчә башкарылмавы өчен җавап бирә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган (гамәлгә ашырыла торган) карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

4.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешма-лары тарафыннан контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәткәндә эшчәнлекнең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе.

5.1. Муниципаль хезмәт алучылар муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы Башкарма комитет хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр тәртиптә Җирлек Башкарма комитетына шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда да мөрәҗәгать итә ала:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза бирүче соратуын теркәү вакытын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын бозу;

3) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен аларны бирү һәм гамәлгә ашыру Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль норматив хокукый актларбелән каралмаган документларны яки мәгълүматны яисә гамәлләр кылуны таләп итү;

4) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда баш тарту нигезләре каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басмадагы хаталар һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозу;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срокларын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору, әгәр туктату нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса.

10) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда, аларның булмавы һәм (яки) дөреслеге күрсәтелмәгән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны яки мәгълүматны таләп итү яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтү.

5.2. Башкарма комитет, Башкарма комитетның вазыйфаи затының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язма рәвештә кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

Шикаять «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлегенең рәсми сайтын (http://krasnokadkinskoe-sp.ru),Татарстан Республикасы дәүләт һәм

муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталын (http://uslugi.tatarstan.ru/),Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталын (функцияләр) http://www.gosuslugi.ru/) кулланып почта аша җибәрелә ала, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә бирелергә мөмкин.

5.3. Башкарма комитетка кергән шикаять аны теркәгән көннән алып унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш, ә Башкарма комитет тарафыннан шикаять бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүчедән документлар кабул итүдә яисә җибәрелгән басмадагы хаталарны һәм хаталарны төзәтүдә яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга шикаять бирелгән очракта - аны теркәгән көннән биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаять үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, яки муниципаль хезмәткәренең исеме;

2) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), гариза бирүче-физик затның яшәү урыны яисә гариза бирүче-юридик затның урнашу урыны, исеме турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты яисә муниципаль хезмәткәрнең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүматлар;

4) аның нигезендә гариза бирүчеБашкарма комитетның,Башкарма комитетның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән килешмәүгә дәлилләр.

5.5. Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләре тәкъдим ителергә мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басмадагы хаталарны һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда алынуы каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарталар.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.7. Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне

кичекмәстән бетерү максатларында, Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында гариза бирүчегә башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре билгеләнгән очракта, шикаять карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат, булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге
Башкарма комитетына

______________________________________

____________________________________

(алга таба - гариза бирүче).
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматы, яшәү урыны буенча теркәлү, телефон)

Белешмә (өземтә) бирү турында
гариза

Сездән__________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
белешмә (өземтә) бирүегезне үтенәм.

______________ ___________ ________________________________________
(дата) (имза) (ФИО)

2 нче кушымта

Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бирүче тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге

Яшәү урыныннан белешмә, хуҗалык кенәгәсеннән өземтә, йорт китабыннан өземтә, алдагы яшәү урынынан белешмә, йорт биләүгә белешмә алу өчен:

1. Шәхесне раслаучы документлар.

Гаилә составы турында белешмә алу өчен:

1. Шәхесне раслаучы документлар.
2. Соратылган адрес буенча теркәлгән барлык гаилә әгъзаларының туганлыгын раслаучы документлар (паспортлар, туу турында таныклыклар, никах теркәү таныклыгы).

Вафат булу көненә вафат булучының яшәү урыныннан белешмә алу өчен:

1. Шәхесне раслаучы документ.
2. Үлем турында таныклыкның төп нөсхәсе.
3. Соратылган адрес буенча теркәлгән барлык гаилә әгъзаларының туганлыгын раслаучы документлар (туу турында таныклыклар, никах теркәү таныклыгы).

3 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Кызыл Чапчак авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесенә
____________________________

**Техник хатаны төзәтү турында**
**гариза**

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм:
___________________________________________________________________________
(хезмәт күрсәтүнең исеме)

Язылган:_______________________________________________________________
___________________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:_____________________________________________________
___________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны җибәрүегезне сорыйм:

электрон документны E-mail:_______ адресына;

___________________________________________________________________________
адресы буенча кәгазьдә почта аша расланган күчермә рәвешендә.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), үзенчәлекләрен бетерү, блокадалау, юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләр), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем вәкилем булган затның ризалыгын раслыйм.

Раслыйм: шәхесемә һәм минем вәкилем булган затка карата, шулай ук түбәндәге минем тарафтан гаризага кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага кушып бирелгән

документлар (документлар күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза биргән вакытта бу документлар гамәлдә һәм аларда дөрес мәгълүматлар бирелгән.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын бәяләү буенча___________телефоннан сораштыруда катнашырга ризалык бирәм.

______________ ________________ ( ________________)
(дата) (имза) (Ф.И.О.)

Кушымта
(белешмә)

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затлар реквизитлары**

**Муниципаль районның Кызыл Чапчак авыл җирлеге Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | **44-50-20** | Krkadka-sp@mail.ru |
| Секретарь | **44-50-20** | Krkadka-sp@mail.ru |